Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN

УНИВЕРСИТЕТ

12+

№30 (81)

3 октябрь 2013 ел

## Укытучылар көне белән!

Университетыбызның бөтен коллективын: студент һәм аспирант, укытучы һәм хезмәткәрләрне искиткеч бәйрәм – Бөтендөнья укытучылар көне белән тәбрик итәм. Бу көн бәйрәм итеп 1994 елда ЮНЕСКО тарафыннан кабул ителә һәм 100дән артык илдә билгеләнеп үтә. Мәгариф өлкәсендә эшләүчеләрнең әлеге һөнәри бәйрәме көнне җәмгыятебез укытучыларга яшьләрне тәрбияләү һәм социаль үсешкә бәяләп бетергесез өлеш кертүләре өчен рәхмәт әйтә. Без барыбыз да кайчандыр укучылар булган кешеләр, шуңа күрә БМБ бу көндә барлык гражданнарны укытучыларының аларның тормышларына ничек итеп йогынты ясаганнары турында уйланырга өнди.

Казан федераль университеты өчен бу бәйрәм зур әһәмияткә ия, чөнки республика һәм Идел буе федераль округы масштабында мәктәп эшен сыйфатлы итеп яңарту миссиясе нәкъ менә безгә йөкләнгән. Бу уңайдан, без яңа – бүленешле – әзерлек моделен гамәлгә ашыра башладык. Аның кысаларында Педагогика һәм психология институты һәм методик җитәкчелек тарафыннан укытучылар профильле институт һәм факультетларга беркетелә. Шуның белән бергә, безнең Алабуга институты традицион һәм челтәрле схема буенча белем бирүне дәвам итә. Ә калган 14 институт 26 программа буенча бүленешле модельне гамәлгә ашыра. Бу исә педагогларга фән компетенцияләрендә зур дәрәҗәләргә ирешергә һәм мәктәпнең барлык фәннәрен колачларга мөмкинлек тудыра.

Хәзер без традицион һәм бүленешле әзерлек формасының өстенлекле якларын бәяли һәм чагыштырып карый алабыз. Безнең максатчан рәвештә тырышуыбыз тиешле нәтиҗәләрен дә бирә. Педагогик юнәлеш буенча укырга теләүчеләр, 2010 елдагы белән чагыштырганда, 55 процентка, БДИ нәтиҗәләре буенча уртача балл күрсәткече ун берәмлеккә артты һәм 70 баллны хасил итте. Бу – илебездә иң яхшы күрсәткечләрнең берсе.

Алга таба бу юнәлешне шулай дәвам итәрбез дип уйлыйм, чөнки җәмгыятебездә (соңгы ун еллыкларда беренче тапкыр) мәктәп укытучыларын, чын мәгънәсендә, хөрмәт итү атмосферасы ныгып килә. Бу – республикабыз җитәкчелегенең педагогларның социаль-икътисади статусларын күтәрүгә юнәлтелгән эшчәнлеге нәтиҗәсе. Университетыбызда булачак укытучыларны әзерләүдә җиде йөздән артык югары квалификацияле педагог хезмәт куя. Аларның 80 проценты – доктор һәм фән кандидаты дигән фәнни дәрәҗәгә ия.

Әгәр потенциалыбыз нигезендә барлык белем бирү звеноларының инновацион юнәлешен һәм үзара бәйләнешен тәэмин итә алсак, без барлык максатларга да ирешәчәкбез. Структур бүлекчәләр составында IT-лицей-интернат, Н.И.Лобачевский исемендәге лицей һәм республиканың уннан артык әйдәп бара торган урта һөнәри белем бирү оешмаларын берләштерә торган фәнни белем бирү кластеры бар һәм безнең бу структураларда эшчәнлегебез гамәли әзерлекне арттыруга юнәлтелгән. Уку йортының фәнни-педагогик секторы тиздән булачак мөһим тарихи вакыйга – Казан университетының 210 еллыгына багышланган чараларны әзерләүгә дә зур өлеш кертер дип уйлыйбыз.

Коллективыбызның барлык вәкилләренә яңа үрләр, җиңүләр, сәламәтлек һәм зур уңышлар телим.

***Ректор И.Гафуров***



Влад Михневский фотолары

# Хөрмәт бәйрәме

Өлкән кешеләр – безнең әти-әниләребез, әби-бабайларыбыз. Алар – бик күп авырлыклар күргән, дөньяның ачысын-төчесен татыган кешеләр. Аларны өлкән булган өчен генә түгел, ә әти-әниләребез, әби-бабайларыбыз булган өчен хөрмәт итәргә тиешбез. **2нче биттә укыгыз.**

## • Вакыйгалар эзеннән

**30 СЕНТЯБРЬДӘ КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНА КЫТАЙ ҮЗӘК ТЕЛЕВИДЕНИЕСЕНЕҢ** (China Central Television – CCTV) **ТӨШЕРҮ ТӨРКЕМЕ КИЛДЕ**. КНР массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре хәзерге вакытта ике документаль фильм әзерли: «Кытайны чит ил гражданнары күзлегеннән өйрәнү» һәм «Бәйләнеш». Аларның сценарийларында Казан университеты да бар. Кунаклар Тарих музее, Конфуций институты һәм «Univer TV» студентлар телевидениесе белән аеруча кызыксындылар.

• • • •

Шул ук көнне **КФУ**да АКШ юристы **ДЖОН ПОГГИНЫҢ** медиация буенча **ЛЕКЦИЯЛӘР КУРСЫ БАШЛАНЫП КИТТЕ**. Алар инглиз телендә мастер-класс форматында үтә. Бу чарада студентлар актив катнашалар һәм медиациянең альтернатив мөмкинлекләре ярдәмендә мәсьәләләрне хәл итүнең практик тәҗрибәсен белләйләр. Чара 9 октябрьгә кадәр дәвам итәчәк.

• • • •

Шушы көннәрдә юридик факультет деканы **ИЛДАР ТАРХАНОВ** «Суд эшчәнлегенә хезмәт итү өчен» **РФ КАЗЫЙЛАР СОВЕТЫНЫҢ КҮКРӘК БИЛГЕСЕ** белән **БҮЛӘКЛӘНДЕ**.

• • • •

Ландшафт экологиясе кафедрасы мөдире, профессор **ОЛЕГ ЕРМОЛАЕВ** «Татарстан республикасы ландшафтлары (Төбәкнең ландшафт-экологик анализы)» фәнни хезмәте өчен, Россия география җәмгыятенең югары бүләге – П.П.Семенов исемендәге **АЛТЫН МЕДАЛЬГӘ ЛАЕК ДИП ТАБЫЛДЫ**.

• • • •

**ЯР ЧАЛЛЫ ИНСТИТУТЫНА** америка укытучысы **ХАННА МИЛЛЕР КИЛДЕ**. Биредә ул студентларга лекцияләр укыячак, аларга инглиз телен өйрәтәчәк. Кунакның Чаллыга визиты уку елы тәмамланганчы дәвам итәчәк. Ханна Россиягә Фулбрайт программасы ярдәмендә килә. Инглиз теленнән кала, галимә рус телендә дә камил аралаша ала.

• • • •

**1 ОКТЯБРЬ** көнне **АЛАБУГА ИНСТИТУТЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ КУРС СТУДЕНТЛАРЫ «СТУДЕНТЛАР ЛИГАСЫ» ВӘКИЛЛӘРЕ БЕЛӘН ОЧРАШТЫ**. Очрашу бик дустанә мөнәсәбәттә үтте. Кунаклар узләре үткәрә торган чараларның видеоязмаларын күрсәттеләр, кызыклы проектлар турында сөйләделәр. Танышу өлешеннән соң, «лига»лылар төрле тренинглар белән беренче курс студентларының күңелләрен күрделәр.

• • • •

Мәгариф һәм фән өлкәсе надзоры буенча **ФЕДЕРАЛЬ ХЕЗМӘТ КФУ**га дәүләт аккредитациясе (№0811) турында **ЯҢА ТАНЫКЛЫК ТАПШЫРДЫ**. Әлеге таныклык нигезендә Казан университетына, аның филиаллар челтәрләре белән бергә, урта һөнәри белем бирүнең нигытылган 8 юнәлеше, бакалавриат буенча югары һөнәри белем бирү әзерлегенең ныгытылган 17 юнәлеше, белгечлек буенча югары һөнәри белем бирү әзерлегенең ныгытылган 18 юнәлеше, магистратура буенча югары һөнәри белем бирү әзерлегенең ныгытылган 12 юнәлеше, аспирантура буенча вуздан соңгы һөнәри белем бирү әзерлегенең 26 юнәлеше һәм өстәмә һөнәри белем бирүнең ныгытылган 7 юнәлеше аккредитацияләнгән.

• • • •

**2-3 ОКТЯБРЬ** көнне Халыкара бәйләнешләр институты **«МӘДӘНИ-ТАРИХИ ФЕНОМЕН БУЛАРАК КҮПМИЛЛӘТЛЕ ТӨБӘК. VI БУСЫГИН УКУЛАРЫ»** халыкара дәрәҗәдәге Бөтенроссия фәнни конференциясе оештырды. Чара профессор Е.Бусыгинның тууына 100 ел тулуга һәм Казан университетының этнология кафедрасының 125 еллыгына багышланды. Конференциянең төп максаты: күпмилләтле дәүләтләр шартларында Россия халыкларының этник үсеш торышына комплексы анализ бирү. Чарада катнашучылар Россиядә этнологик белем бирү, фән тарихы һәм этнографик музейларны өйрәнү, этнологиянең башка фәнни дисциплиналар белән бәйләнеше, Идел-Урал халыкларының традицион мәдәнияте һәм тарихы, күп этникы төбәкләрдә этникаара бәйләнешләр мәсьәләләре буенча фикер алыша.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*

## • Өлкәннәр көне

# Хөрмәт бәйрәме

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

1 ОКТЯБРЬ КӨННЕ ИЛЕБЕЗ ӨЛКӘННӘР КӨНЕН БӘЙРӘМ ИТТЕ. БУ ЧАРАДАН БЕЗНЕҢ УКУ ЙОРТЫ ДА ЧИТТӘ КАЛМАДЫ.

Университетыбызда барлыгы 1250дән артык ветеран исәпләнә һәм аларны һәрвакыт истә тоту, зурлау матур традициягә әверелде. Студентлар һәм хезмәткәрләр әзерләгән концерт программасы өлкәннәребез өчен зур рухи бүләк булды.

Шушы зур бәйрәм уңаеннан, уку йортыбыз базасында эшли торган Өченче буын университетында да яңа уку елы башланды. 2007 елда старт бирелгән әлеге проект бүгенге көндә 15 программа буенча белем бирә һәм анда 2500 «студент» укый.

Бу бәйрәм олы яшьтәгеләргә карата ихтирам, хөрмәт, наз кебек сыйфатларны уята һәм ике арадагы мөнәсәбәтне тагын да ныгытып җибәрүдә этәргеч булып тора. Тик бүгенге көндә бу мөнәсәбәтләр алдыбызга кайбер проблемаларны да куя. Алар – безне, без – аларны аңлап бетермибез. Ә бу нидән килә соң? Шундый сорау белән уку йортыбызның хөрмәтле хезмәткәре, Университетыбыз Ветераннар советы рәисе Илгиз абый Абдуллинга мөрәҗәгать иттем. «Өлкәннәр көненең максаты булып, буыннарны якынайту тора. Өлкән буын хәзерге яшьләрне каты бәгырьле ди, ә яшьләр өлкәннәрне гаепли. Минемчә, ике якта да гаеп бар. Элдән-ел атаана тәрбиясе азая бара сыман. Әхлаксыз эти-әни әхлаклы бала тәрбияли алмый. Ә бу – өлкән буын бурычы. Яшьләр игътибарсыз, тәрбиясез, дип утырсак, куелган максатка ирешеп булмаячак. Хөкүмәттә яшь буынны тәрбияләү идеологиясе булырга тиеш. Хәзер бит телевидениедә дә тәрбиягә зур урын бирелми. Боларның барысы да өлкән һәм яшь буынның кыйммәти юнәлешләре арасын бозуга китерә. Ә бит сез бездән үрнәк алырга тиеш. Өлкәннәр хәзердән үк яшьләрне тәрбияләүдә катнашса, ике буын якынаер иде. Шулай итеп илнең хәле дә яхшы якка үзгәрер иде. Кайберәүләр үз әти-әниләрен картлар йортына илтә. Бу бик ямьсез күренеш. Ни генә дисәк тә, яшьләр өлкәннәргә карата мәрхәмәтле, ярдәмчел булырга тиеш. Бу эштә барыбыз да, шулай ук студентлар да актив катнашырга тиеш, чөнки студентлар – җәмгыятьнең «каймагы». Балага тәрбия, иң беренче чиратта, гаиләдә бирелә. Гаиләнык булса, ил дә нык була», – дип, фикерләре белән уртаклашты Илгиз абый.

Олыларга хөрмәт кыл, кечеләргә шәфкать кыл, ди халык мәкале. Өлкәннәребезне бәйрәм көнендә генә түгел, ә һәркөнне зурласак, хөрмәтләсәк иде. Алар безнең үткәнебез, ә үткәнен оныткан кешенең киләчәге юк!

## • Эшнең төше

# Машина – үсеш чыганагы

КИЧӘ «КОРСТОН» СӘУДӘ ҮЗӘГЕНДӘ МАШИНА ТӨЗҮЧЕЛӘР КӨНЕНӘ БАГЫШЛАНГАН ТАНТАНАЛЫ ЧАРА УЗДЫ. БӘЙРӘМГӘ БАГЫШЛАНГАН КҮРГӘЗМӘДӘ КФУ РЕКТОРЫ И.ГАФУРОВ ҖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘГЕ ДЕЛЕГАЦИЯ ДӘ КАТНАШТЫ.





Машина төзелеше – алга киткән теләсә-кайсы илнең төп икътисади, сәнәгать тармагы, индустрия үзәге булып тора. Әлеге өлкәдә эшләүчеләр һәр елны сентябрьнең соңгы якшәмбесендә һөнәри бәйрәмен уздыра.

Бүгенге тормышны машина төзүчеләрдән башка күз алдына китереп булмый. Хәзер автомобиль шул дәрәҗәдә безнең көнкүрешкә кереп китте, әйтерсең, без җәяү йөри белмибез. Машина йөртә белгән кеше гомеренең ахырына кадәр аңа гашыйк була һәм тимер ат безнең иң якын дуска әйләнә. Машина ул – шәхси генә түгел, җәмгать, авыл хуҗалыгы транспорты. Ә аларның маркаларын саный башласаң?! Аларның һәркайсы машина төзүчеләр тырышлыгы белән барлыкка килгән.

Машина төзелешен автомобильләр чыгару белән генә бәйләп карарга ярамый. Әлеге өлкә кешеләре безне төрле станок һәм җиһазлар, төш реакторлары, су асты көймәләре, космик кораблләр, тузан суырткыч, кер юу машиналары һ.б. белән тәэмин итәләр.

Күргәзмәдәге презентацияләр республикабызда техник фәннең алга китүе, яшьләрнең бу өлкәдә аеруча актив эшләве турында сөйли. Ә Татарстан Республикасы Россиянең алдынгы машина төзү комплексы булып тора. Бәйрәм уңаеннан Корстонда оештырылган күргәзмәдән Казан федераль университеты да читтә калмады: инженерия белеменә багышланган презентация тәкъдир итте.

*Влад Михневский фотолары*

## • Чара



Влад Михневский фотосы

# Төп басым – белем бирүгә!

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

1 ОКТЯБРЬ КӨННЕ КФУ ФӘННИ БЕЛЕМ БИРҮ КЛАСТЕРЫНЫҢ КООРДИНАЦИОН СОВЕТЫ УТЫРЫШЫ БУЛДЫ. ЧАРАДА КФУ РЕКТОРЫ И.ГАФУРОВ ТА КАТНАШТЫ УЗДЫ. АНЫ ТР ПРЕМЬЕР-МИНИСТРЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ УРЫНБАСАРЫ РАВИЛ МОРАТОВ АЛЫП БАРДЫ.

Премьер-министр урынбасары кереш сүзендә республика икътисадының инновацион үсешен модернизацияләргә, әзерлек системасына үзгәрешләркертергә кирәк дип әйтте: «Төп басым белем бирүгә ясалырга тиеш һәм КФУның нәкъ менә бу юнәлештә атлавы зур әһәмияткә ия. Уку йортының үз эшчәнлегендә яңа идеяләр, инновацион элементларны актив рәвештә куллануы да уңай күренеш».

И.Гафуров университет өчен әле яңа булган инженерлык һәм педагогик белем бирү юнәлешләре, аларның үсеш-үзгәреше турында сөйләде. «Без, традицион метод белән бергә, яңача укыту формаларын гамәлгә ашырабыз. Шул рәвешле аларның уңай якларын даими рәвештә күзәтеп һәм чагыштырып бара алабыз», – дип билгеләде ректор.

Алга таба инновацион эшчәнлек буенча проректор Н.Кашапов университетта инженерия белемен бирү процессы, аның структурасы турында мәгълүмат бирде һәм төп максатны ачыклады: «Иң мөһиме – студентларда инженерлык күнекмәләрен булдыру. Һәм безнең төп бурыч: моның өчен шартлар булдыру».

Яр Чаллы институты директоры М.Ганиевның чыгышы автомобиль төзү өчен инженер-техник белем бирүгә багышланды. Педагогика һәм психология институты директоры А.Калимуллин һәм Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге директоры Р.Шәйхелисламов дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә ашыру шартларында әзерлек системасы һәм квалификацияне күтәрүне модернизацияләү турында сөйләделәр.

Чараның йомгак өлешендә әлеге өлкәләрне тагын да алга җибәрү өчен, күбрәк мәктәпләр белән эшләргә, укучыларда кызыксыну уятып, лаеклы абитуриент тәрбияләргә кирәк дигән нәтиҗәгә киленде.

• Укытучылар көне

# Остазларның остазы сез, Васил абый!

**Раил САДРЕТДИНОВ,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Укытучы нинди сыйфатларга ия булырга тиеш? Гомумән, ул нинди кеше? Киенлык тудыра торган сорау, минемчә. Димәк, бу сорауга берьяклы гына җавап биреп булмый. Дөрес, минем моңарчы да үз-үземә бу сорауны биргәнем булды. Тик әле һаман җавап кына таба алганым юк.

Минемчә, укытучының чын эталоны, идеалы мәктәп тормышының беренче көненнән үк билгеле була башлый. Бу укытучы кызыклы итеп сөйли, аңлата белә, ә менә моның дәресендә берни дә аңламый утырам, дияргә ярата күп кенә мәктәп укучылары. Мәктәпне тәмамлап, югары уку йортына кергәч, бу мисаллар тагын да конкретрак була башлый һәм менә шунда инде син чын укытучыга хас сыйфатларны тәмам тәртипкә салып бетерәсең.

Студент халкы бик сизгер бит ул. Ул, мәктәп укучысы сыман, күнелсез дәрес, лекция алып бара торган остазының дәресенә үзен мәҗбүриләп килеп тормый. Килсә дә, билгеләнер өчен генә килә һәм ахырда барыбыр комачаулап кына утырачак.

Бүген мин чын остаз, укытучы идеалын үзем укый торган татар журналистикасы кафедрасын җитәкләүче профессор, филология фәннәре докторы Васил абый Гарифуллинда күрәм. Бу бүлекне тәмамлаган яки шушында укучыларның кайсыннан гына килеп сорама, барысы да Васил абыйны бары тик уңай яктан гына тасвирлап бирер. Чыннан да, ул – университетта безнең икенче әтиебез. Ул гадилеге, ачыклыгы, һәрбер студентка юл таба белүе белән үзенә тартып тора. Аңа нинди генә сорау белән килмә, уңай җавап аласыңа шик юк. Кафедра ишеген атлап кергәч, җылы, дустанә атмосфера каршы ала. Укытучыларыбыз янына да без ниндидер җитәкче янына килгән сыман килмибез. Алар безгә үз коллегалары итеп карый. Боларның барысы да кафедра җитәкчелегеннән тора бит!

Васил абыйның дәресләренә килгәндә, алар бик күңелле үтә. Остазыбыз безне, дәрес бирү белән генә чикләнмичә, зур тормышка да әзерли, шактый чытырманлы журналистика өлкәсендә нинди ялгышлыклардан сакланырга кирәклеге турында да искәртә.

Әле дә хәтеремдә, иң беренче көнне укырга килгәч, коридорда очратып хәл-әхвәл сорашып йөрүче бу укытучыны танымаган идем. Аннан мин аның безнең кафедра җитәкчесе икәнлеген белдем. Тик шунда ук күңелне бер шик биләп алды: «Җитәкче кеше гади студентлар белән кул бирep күрешеп, хәл-әхвәл сорашып йөри ди мени инде?!» Йөри икән шул, нәкъ тә шулай. Еллар үткән саен, мин Васил абый кебек булырга кирәклеген төшенә барам. Чөнки гадилек – ул иң зур матурлык.



**Алисә Сабирова, 4 курс:**

*«Васил абый бик кешелекле педагог, җитәкче. Укуның беренче елларында безнең өчен ул бик усал, кырыс кебек тоелды. Әле дә имтихан вакытында һәрберебезнең дәфтәр битен карап, парта асларына яшереп куйган «шпаргалкаларыбызны» җыеп йөргәне хәтердә. Нигъдер, бик курка идек без аннан. Соңыннан инде, аның дәресләрендә бер кат сыналгач, мыек астыннан елмаюын да күрсәтә башлады.*

**Ләйсән Солтанова, чыгарылыш-2013:**

*Васил абый, миңа калса, уникаль шәхес. Аңарда чиксез гыйлем дә, шаян күңел, журналистлык кына түгел, хәтта актер осталыгы да (аудиториягә ишек шакып керүеннән һәр студентның дәрес буе кәефе яхшы була иде!), нечкә күңеллелек, сабырлык, олы йөрәкле булу – барысы да бар... Аның үз әченә сыйдырган һәм сокландырган сыйфатларын санап бетерерлек түгел. Бер сүз белән, ул – остаз. Нәкъ менә хикәяләрдә сурәтләнә торган, укучылар хәтерендә онытылмаслык эз калдыручы мөгаллим ул!*

**Рания Садыйкова, чыгарылыш-2013:**

*Факультетта иң күңелле һәм позитив кешеләрнең берсе ул – Васил абый. Орышса да, ачуланып орышмый бит ул, яратып әрли. Шуның өчен бик хөрмәт итә идек аны һәм хәзер дә шундый ук мөнәсәбәттә.*

• Белем баскычлары

1 октябрь уку йортыбыз аспирантлары өчен аеруча шатлыклы һәм онытылмас көн булып истә калыр. Бу көнне Актлар залында аларга тантаналы төстә таныклыклар тапшырылды.

# Югары белемнең иң югары ноктасы

**Илмир ВӘЛИЕВ,** хәбәрче

Беренче булып аспирантларга сәламләү һәм тәбрикләү сүзләрен КФУ ректоры Илшат Гафуров җиткерде: «Аспирантлар – университетыбызның иң сәләтле һәм креатив яшьләре. Сезнең өчен безнең университет бик күп мөмкинлекләр ача. Аспирантурада уку – иң беренче чиратта, чит ил уку йортлары белән хезмәттәшлек итү, анда барып, тәҗрибә тупау, фәнни лабораторияләрдә эшләү һәм яңа дуслар табу. Вакытыгызны бушка түгел, ә киләчәгегезне, фән өлкәсендә исемегезне булдыру өчен уздырыгыз». Университетның фән өлкәсендәге уңышлары белән фәнни эшчәнлек буенча проректор Д.Нургалиев таныштырды. Ул студентларга һәм аспирантларга ачылган мөмкинлекләр, дәүләт тарафыннан эшләп килә торган яшь галимнәргә ярдәм күрсәтү программалары турында җентекләп сөйләп, югары белемнең иң югары баскычында укучыларга уңышлар, яңа һәм файдалы ачышлар теләде. Аспирантура һәм докторантура бүлеге җитәкчесе Е.Нуриева да тантананың сәбәпчеләренә җылы сүзләрен, изге теләкләрен әйтте.

Аспирантлар өчен иң күңелле һәм тетрәндергеч мизгелләр алда иде, чөнки аларга, тәбрикләү сүзләреннән соң, таныклыклар тапшырылды. Бу шатлыклы мизгелләр залда утыручылар өчен бик мөһим һәм күптән көтелгән икәнлеге аларның күзләреннән үк күренеп торды.



Влад Михневский фотосы

Педагогика һәм психология институты аспиранты Алинә Нафикова шатлыгын яшерә алмыйча: «Беренчедән, аспирантура карьера үсешенә оптималь мөмкинлекләр бирә. Икенчедән, мәгариф өлкәсендә эшләүчеләргә хезмәт хакларына өстәмә процентлар өстәлә. Кандидатлык дәрәҗәсе киләчәктә мәктәптә эшләргә теләгән укытучыга бик зур плюс булып барачак. Өченчедән, үзеннең фәнни омтылышларыңны тормышка ашыру өчен, грантлар оту, фәнни лабораторияләрдә эшләү, төрле конференцияләрдә, бәйгеләрдә катнашу, чит илләрдә тәҗрибә туплау мөмкинлеге дә бирә. Бу мизгелләр минем өчен бик шатлыклы, чөнки бюджет урынына эләгү өчен, бик зур конкурс аша узарга туры килде. Бүген шушы тарихи залдагы чарада катнашуыма чиксез шатмын», – диде.

• Тарих әзләреннән

# Татар укытучылары «фабрика»сы

Сәхифәне **Ләйсән ИСХАКОВА** әзерләде

Патша заманнарында башлангыч мәктәп өчен укытучыларны Казанда берничә җирдә әзерләгәннәр: укытучылар институтында, укытучылар семинариясендә, керәшен татарларының укытучылар мәктәбе һәм татар укытучылар мәктәбендә. Казан татар укытучылар мәктәбенә нигез 1876 елда салына.

Берәдә татарларны рус телендә укытканнар, Идел-Урал төбәгендәге башлангыч татар училищелары өчен укытучылар әзерләү белән шөгыльләнгәннәр. Әлеге уку йортын ачуда татар мәктәпләре инспекторы В.В.Радлов төп әйдәп баручы булган. Ул мәктәпнең уку-укыту бүлеген җитәкләгән, педагогика, дидактика, тарих фәннәрен укыткан. В.Радлов бу мәктәпне бөтен татар халык мәктәпләренең төп мәктәбе итеп күрергә хыялланган.



1876-1917 еллар аралыгында мәктәп барлыгы дүрт йөздән укытучы әзерләп чыгарган. Уку 4 ел дәвам иткән. Беренче сыйныфта – рус теле, арифметика, дин дәресләре, икенче сыйныфтан боларга тарих, география өстәлгән, ә өченчедән педагогика һәм дидактика буенча белем бирелгән. Рәсем, сызу, гимнастика белән дә шөгыльләнгәннәр.

Мәктәпкә 15 яше тулган ир балаларны алганнар. Беренче чыгарылыш 1880 елда булган. Ул чакта мәктәпне нибары 5 кеше тәмамлаган. XIX гасырның 90 еллар ахырына кадәр бу сан әллә ни үзгәрми. Әмма XX гасыр башында укырга керергә теләүчеләр саны кисәк кенә артып китә: 1901 елда 26 укучы булса, 1903 елда – 47 кеше. Мәктәптә дворян, рухани, сәүдәгәр, мещан һәм крестьян балалары белем алган. Шулай да белемгә омтылучылар арасында крестьяннар күпчелекне тәшкил иткән.

Бирәдә үз вакытының алдынгы карашлы авторитетлы педагоглары белем биргән. Алар арасында мәктәпнең беренче инспекторы Мөхәммәтгали Мәхмүтов; педагогика һәм рус теле укытучысы, соңрак инспектор вазифасын башкарган Михаила Пинегина, рус теле укытучысы Ибраһим Терегулов; дин нигезләренә төшендерүче Шиһабетдин Мәрҗани; рәсем һәм чиста язуга өйрәтүче Шакирҗан Таһиров шәхесләре аерым урын тота.

Мәктәпне оештырып җибәрүдә күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйри да катнашкан. 1877 елда М.Мәхмүтов Казан укыту округы вәкиле П. Шестаковка хатында болай дип яза: «Казан ир балалар мәктәбендә рус теле укытучысы вазифасын башкаручы К.Насыйров мин җитәкләгән укытучылар мәктәбенә татарча язулы ярымшарлар һәм дөньяның биш кисәге карталарын тапшырды. Язулар аның үзе тарафыннан язылган һәм төзүченең зур хезмәтен таләп иткән. Алар география укытканда файдалы булырга мөмкин».

Әлеге мәктәп татар интеллигенциясенең мәдәни-белем бирү үзәге булып саналган. Аны тәмамлаучылар арасында күренекле сәясәтче һәм дәүләт эшлеклеләре дә булган. Икенче Дәүләт Думасы депутаты К.Хәсәнов, татар милли-азатлык хәрәкәте әйдаманнарының берсе С.Максуди, язучы Г.Коләхмәтов, Г.Исхакый, химик-органик Г.Камай үз вакытында татар укытучылар мәктәбендә укыган. Алга таба нәкъ менә алар милли мәдәниятне, халык мәгарифен үстерүдә зур көч куйган.

**Әдәби сәйләннәр**



Бүген сәхифәбезне укытучылар ижатына багышларга булдык. Халисә Ширмән дигән шәхес турында белмәгән кеше юктыр!

Халисә Ширмән (Халисә Хатыйп кызы Ширманова) 1969 елның 8 июнендә Лениногорски районы Зәй-Каратай авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлагач, комсомол чакыруы буенча бер ел «Уныш» колхозында эшли, аннары КДУның татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультетында белем ала. Шул көннән башлап, гомерен студентларга белем бирүгә багышлый. Татар әдәбиятына бик күп талантлы яшьләр алып килгән «Әллүки» әдәби ижат берләшмәсенең житәкчесе булып тора. Остазыбыз – дүрт китап авторы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Х.Ширмән әсәрләре буенча «Язмышлардан узмышлар юк», «Кайтаваз», «Ерактагы йолдызым», Нурания Жамали белән берлектә язылган «Бәхетлеме син?» исемле телевизион фильмнар төшерелде.

## *Мин генәме?*

*Ә кем әйткән көзге яңгырларны*
*Соры төстә диеп, гел генә?*
*Кайтам менә урам уртасыннан,*
*Өсләремә энҗе түгелә...*

*Һәр тамчысы көзге бу яңгырның*
*Уттай кызган җанга төшә дә,*
*Күтәрелә кире төнге күккә...*
*Сөйләп булмый моны кешегә.*

*Ә җан дигән нәрсә ник кызган соң?*
*Мәхәббәттән инде, билгеле:*
*Тагы күңел гашыйк бу дөньяга,*
*Ләйләсенә Мәҗнүн шикелле.*

*Соры түгел шуңа тамчылар да.*
*Тоташ актан болыт киенгән.*
*...Мин генәме әллә бу дөньяда*
*Көзге яңгырларга сөенгән?*

*  *  *

*Унсигездә кызлар шундый гүзәл:*
*Сызмаса да, кыйгач кашлары,*
*Зифа буе, толым-толым чәче...*
*Әйләнәдер егет башлары!*

*Утызда да матур әле алар,*
*Тулып пешкән чия шикелле.*
*Кулларында бала тибрәтәләр –*
*Шундый гүзәл, шундый сөйкемле!*

*Кырыкта да чибәр ханымнар бар,*
*Каян килә икән матурлык?*
*Ә илледә матур булу өчен*
*Кирәк, ахры, чиксез батырлык...*

*Исең китми усал җыерчыкка,*
*Күзләреңнән тамса бәхетең,*
*Шул буладыр алтмыш матурлыгы –*
*Каршы алу картлык сәгатен...*

*Әби булсам, матур булачакмын!*
*Шундый карар бирдем үземә.*
*«Әй, бәхетле булган тормышы», – дип,*
*Соклансыннар карап йөземә...*

***

*Син килмисең... Белә, йөрәгеңдә*
*Башка йөзләр урын алгандыр.*
*Миңа булган кайнар хисләреңнән*
*Тик күмерләр генә калгандыр.*

*Көтәм әле... Беркөн минем дә бит*
*Күңел тынар, хисләр таркалыр.*
*Бер йолдызчык сүнәр, бәлки, күктә,*
*Йөргән сукмакларда моң калыр...*

*Һичкемнең дә эше булмас бездә.*
*Кышкы шәфәкъ әйтер сәламен...*
*Тик тәрәзгә Салкын язып китәр*
*Бу романның моңсу дәвамын...*

*Нинди кайнар хисләр юкка чыга.*
*Нинди сүзләр җилгә сибелә!*
*Кавышканнар моны белми булыр.*
*Беләбез тик мин дә син генә...*

## *Аһ,бу дөнья!*

*Миллион еллар элек*
*Матур булгансыңдыр тагын да!*
*Табар өчен нәсел-нәсәбемне*
*Җырлап кайтам туган ягыма...*

*Ханнар узган, Урдаларга туктап,*
*Сугышлыда корал алышкан...*
*Ә мин кайтам атсыз, җәя-уксыз,*
*Итегемә дала ябышкан...*

*Ябышкан да дала, Син – типтәр! дип*
*Язып куймак булган маңгайга!*
*...Ә йөрәктә никтер урман моңы,*
*Таулар җыры сызыла уңайга...*

*Белмим, дала. Әйтә алмыйм әле,*
*Кайда оям, кайда багалмам?*
*Бөркетме мин, әллә чаптар атмы,*
*Кайсы юлда икән югалмам?*

*Итегемне юып инешемдә,*
*Таугa менгәч, уйлап карармын:*
*Типтәре дә, башкорты да түгел,*
*Мин – баласы газиз дөньяның!..*

***

*Уңга китсәм – мине нилэр көтә?*
*Сулга китсәм - кемнәр яралар?!*
*Бер атлыйм да, кинәт туктап*
*калам...*
*Ә кешеләр алга баралар...*

*Ә кешеләр һаман ашыгалар,*
*Гомер бит ул, диләр, бер килә!*
*Уңга-сулга, артка карап*
*торсаң,*
*Ерак китәрмендер мин, димә...*

*Нигә шундый кыюсызмын икән,*
*Нигә миндә юк ул эрсезлек?*
*Эрсезләрнең аяк атлавыннан*
*Сибелеп кала сыман ямьсезлек...*

*Уңга карап, сәлам бирәм көнгә,*
*Сулга борылып, үбәм гөлләрне.*
*Дөнья бик зур, әмма минем*
*кебек*
*Табалмассыз башка юләрне...*

*Ярый әле, шундый булганмын мин.*
*Күрем – таҗдай, җирем –*
*пайтәхет.*
*Дөнья матурлыгын күрә белү –*
*Шуннан олы бармы соң бәхет?!*

*Күбәләкнең канат җиленнән дә*
*Әрфиядәй күңел җилкенә.*
*Хан кызы күк горур атлыйм*
*мендә,*
*Битем куеп җилләр иркенә...*

## ЧӨНКИ

*Мин – баласы гүзәл*
*табигатьнең,*
*Сәхифәсе китап-җиһанның.*
*Бите саен минем дә бер әкият,*
*Бите саен тылсым ич аның...*

*...Уңга китсәм – мине язлар көтә,*
*Сулга китсәм – ап-ак буранна...*
*Ишетә белгәннәргә бу дөньяда*
*Әллә нинди гүзәл моңнар бар...*

**Безнең канат**

# Белем нуры өләшүчеләр

**Наталья ПАНКРАТОВА,** 11 С сыйныфы

Илебез 50 елдан артык Укытучылар көнен бәйрәм итә. Бу көнне хөрмәтле укытучыларыбызны зурлыйбыз, рәхмәт сүзләре җиткерәбез, төрле бәйрәм чаралары уздырабыз.

КФУның Н.И.Лобачевский исемендәге лицеенда иң яхшы укытучылар эшли. Аларны зурлау өчен, 2 октябрь көнне бәйрәм тантанасы уздырдык. Урамда нибары биш градус җылы, ә лицей эчен мөгаллимнәребез елмаюы кояш нурлары кебек җылытып һәм нурландырып торды. Гомумән, бәйрәмдә катнашкан һәркемнең йөзендә шатлык чаткылары балкыды. Әйтерсең, лицейның диварлары да елмая. Алар матур чәчәкләр, котлау сүзләре язылган газеталар, шарлар белән бизәлгән иде.

Чарага һәр сыйныф бик җитди итеп әзерләнгән. Бәйрәм төрле номерлардан торган концерт белән үрелеп барды. Укытучылар өчен яңгыраган һәр җыр, башкарылган дәртле биюләр алар күңеленә хуш килгәндер дип уйлыйбыз.

Шатлык белән бергә, укытучыларның йөзләрендә күз яшьләре дә күренде. Унберенче сыйныф укучылары өчен дә моңсу булып китте. Бу бит безнең өчен лицеебызның ныклы канаты астында үтә торган соңгы ел. Монда узган һәр мизгелнең, дәресләрнең, белем бирүче остазларыбызның безгә ни дәрәҗәдә кадерле һәм якын булуы турында сүзләр белән генә әйтеп булмый. Рәхмәт сезгә, яраткан укытучыларыбыз!



*Замананың авырлыкларына кармастан, кайберәүләр дүрт-биш балага яхшы тәрбия бирә, ә кемнәрдер бер бала да тәрбияли алмый. Укытучы... Ул кеше баласы өчен җаваплы... Укытучы кулында бер бала язмышы гына түгел. Укытучы кулында дистәләгән, йөзләгән, меңнәрләгән бала язмышы һәм киләчәге. Дан һәм хөрмәт Сезгә, мөгаллимнәребез!*

**Яшьлек-янарыш**

# Күңелле яшибез!

**Энҗе СӨЛӘЙМАНОВА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Университет. Дәресләр. Бер кочак китап-дәфтәр. Ашыга-ашыга лекцияләр язу. Студент тормышын күпләр шулай күз алдына китерә. Хәер, бу – дөрес күзаллау. Әмма Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтында укучыларның уку рәвешләре күпкә кызыклырак.

Уку белән бергә, практиканы дә бәйләп алып барабыз без. Һәрдаим телевидение, радио, газета-журнал эшчәнлеге белән дә танышып торабыз. Дәресләр вакытында төрле очрашулар үтә. Үзебез дә кунакка йөрергә яратабыз.

1 октябрь көнне без, татар журналистикасы бүлегенең 2 курс студентлары, «Шәһри Казан» газетасы редакциясенә кунакка бардык. Баш мөхәррир Мансур абый Мортазин һәм журналистлар белән очраштык, үзебезне кызыксындырган сорауларга җаваплар таптык. Редакция эшчәнлеге белән яхшы таныш булсак та, «Шәһри Казан»да үзебез өчен күп кенә яңалыклар ачтык.

«Журналистиканың нигезен тел тәшкил итә. Матур язу өчен, әдәби әсәрләр күп укырга кирәк. Фикерләү сәләте, тел һәм тырышлык булса, син яхшы журналист була аласың. Журналистиканың нигезендә газета-журнал ята. Шуңа күрә иң катлаулысы: газета-журналда эшләү. Әмма бүген күпләр телевидение, радиога агыла. Ә бит яза белми торып, безнең һөнәрдә уңышка ирешеп булмый. Яза белгән кеше ул кайда да булдыра ала», – дигән фикерен белдерде Мансур абый.

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.